КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1047

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.3.12 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6.3.13 пунктында «план нигезендә» сүзләреннән соң«, шулай ук балалар фикерен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

8.4.2 пунктында «18 яшьтән 40 яшькә кадәрге яшь инвалидларга» сүзләрен «18 яшьтән 50 яшькә кадәрге инвалидларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы «Картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, аларның тасвирламасы һәм күләмнәре» таблицасының 1.12 пунктындагы 4 графасында «0, 1» саннарын «0, 1, 2, 3» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, аларның тасвирламасы һәм күләмнәре» таблицасының 1.12 пунктындагы 4 графасында «0, 1» саннарын «0, 1, 2, 3» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасындагы «Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә (гаиләдә чит кешенең каравына даими мохтаҗ инвалид (инвалид бала) булуга бәйле рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнардан тыш) социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, аларның тасвирламасы һәм күләмнәре» таблицасының 4.3 пунктындагы 3 графасына «, китаплар, журналлар, газеталар бирү, өстәл уеннары оештыру» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин